УДК 930.2 DOI: 10.22378/he.2018-3-2.319-325

# «ТАТАР ТАРИХЫ ТИҢДӘШЕН КҮРМӘГӘН ДАҺИ» («ВАКЫТ» ГАЗЕТАСЫ Ш. МӘРҖАНИ ЮБИЛЕЕ ТУРЫНДА)

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә күренекле татар мәгърифәтчесе һәм галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең 100 еллык юбилее мөнәсәбәте белән «Вакыт» газетасында басылган мәкаләләр барлана, аларга анализ ясала. Аерым алганда, Мәрҗанинең тормыш юлы һәм фәнни-педагогик, иҗтимагый эшчәнлегенә, аның юбилеен оештыру һәм үткәрү, исемен, мирасын мәңгеләштерү мәсьәләләренә караган материаллар тикшерелә. Әлеге мәкаләләрне өйрәнү XX гасыр башында Ш.Мәрҗани шәхесенең төрки-татар, мөселман дөньясында ни дәрәҗәдә югары урын тотканлыгын тагын бер кат расларга мөмкинлек бирә.

**Төп төшенчәләр:** Шиһабетдин Мәрҗани, татар матбугаты, «Вакыт» газетасы, юбилей, истәлекне мәңгеләштерү.

Шиһабетдин Мәрҗанинең күпкырлы эшчәнлеге һәрчак җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә торган. Вакытлы матбугатта, аерым алганда төрки-татар матбугатында, Мәрҗани турында мәкаләләр басылып торган. Галимнең 100 еллык юбилее якынлашканда мондый язмалар ешрак күренә. Ш.Мәрҗанинең юбилеен зурлап билгеләп үтү мәсьәләсе 1912 елда ук күтәрелә, әзерлек эшләре дә шул елда башлана. 1914–1915 елларда, Ш.Мәрҗанинең тууына һиҗри календаре буенча 100, вафатына милади буенча 25 ел тулу уңаеннан, мондый материаллар аеруча күп басыла башлый[1].

Татар вакытлы матбугатында дөнья күргән мәкаләләрдә төп ике юнәлешкә игътибар ителә: беренчесе – татар халкын, киң җәмәгатьчелекне Шиһабетдин Мәрҗани шәхесе, аның тәрҗемәи хәле һәм эшчәнлеге, иҗади мирасы белән тулырак таныштыру. Бу юнәлештә бигрәк тә «Кояш», «Йолдыз», «Ил» газеталарын, «Сөембикә» һәм «Шура» журналларын аерып күрсәтергә мөмкин. Икенче юнәлеш – мәгърифәтче-галимнең юбилеен

[1] Һиҗри ел исәбе буенча 1915 елда Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 100, милади ел исәбе буенча 1914 елда вафатына 25 ел була.

оештыру һәм билгеләп үтү мәсьәләсе. Әлеге проблема татар җәмәгатьчелеген аеруча кызыксындырган: Ш.Мәрҗани дәрәҗәсендәге олуг галим һәм җәмәгать эшлеклесен тиешенчә искә алу, рухы алдында баш ию, аның хезмәтләрен киң даирәләрдә таныту, истәлеген саклау һәм киләчәк буыннарга җиткерү төрки-мөселман дөньясында иң мөһим эшләрнең берсе буларак каралган.

Вакытлы матбугатта күренгән язмаларда мәрхүмнең ядкярен саклау, олылау, игелекле гамәлләр башкару мөһимлеге ассызыклана. Әйтик, 1912 елның 21 февралендә Әстерханда чыга торган «Идел» газетасында басылган «Шиһаб хәзрәт Мәрҗани җәнабларының юбилее мәсьәләсендә даир» мәкаләсендә Ш.Мәрҗани юбилеена багышлап түбәндәге эшләрне башкару тәкъдим ителә: 1) шәһәрнең бер мәктәбенә аның исемен бирү; 2) Мәрҗани исемен йөртүче зур бер һөнәр мәктәбе ачу; 3) Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге стипендия булдырып, берәр мәктәптә, гимназиядә яисә реальный училищеда укучы бер татар баласын (студентын) бүләкләү [8].

Танылган, күренекле шәхесләрнең истәлеген мәңгеләштерү проблемасы XX гасыр башында төрки-татар дөньясында шактый актуаль мәсьәләләрнең берсе булып торган. 1914 елда, мәсәлән, мәшһүр мәгърифәтче һәм педагог Исмәгыйль Гаспралы вафатыннан соң да татар газеталарында аның истәлеген, исемен мәңгеләштерү, хезмәтләрен алдагы буыннарга җиткерү максатыннан татарлар өчен Гаспралы исемендәге мәктәп ачу, стипендия булдыру һәм башка шундый чаралар уздыру турында мәкаләләр, тәкъдимнәр шактый күп басыла [1; 3; 5].

Ш.Мәрҗани һәм аның юбилеен уздыруга бәйле материалларны Оренбург шәһәрендә дөнья күргән «Вакыт» газетасында да еш очратырга мөмкин.

«Вакыт» газетасы укучыларны Ш.Мәрҗани юбилеен үткәрүгә әзерлек эшләренең торышы, үтәлеше белән һәрдаим таныштырып тора. Әйтик, 1914 елның 18 апрелендә чыккан «Мәрҗани юбилее» мәкаләсендә Шиһабетдин Мәрҗани юбилеена әзерлек эшләре уңышлы дәвам итү турында хәбәр ителә, «галим хакында олуг мөкәммәл әсәрнең 100 сәхифәдән артыгы басылып чыгуы», Мәрҗанинең юбилеен алдагы елның 15 гыйнварына билгеләү мәсьәләсе хәл ителү турында әйтелә. Галимнең вафатына 25 ел тулу шушы көннәргә туры килсә дә (18 апрель), аны зурлап билгеләп үтүне кичектереп торып, киләсе елның гыйнварында ике юбилейны бергә уздыру урынлы булачагы турында хәбәр ителә [4].

Укучыларны Ш.Мәрҗани мирасы белән таныштыру максаты белән шушы ук санда күренекле педагог, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Җамалетдин Вәлидинең «Мәрҗани» дигән зур күләмле мәкаләсе басылып чыга [2]. Шактый тулы мәгълүматлы бу хезмәттә Мәрҗанинең аерым әсәрләренә җентекле анализ ясала. Автор «Тарих ирләрне тудырамы, әллә ирләр үзләре тарихны тудырамы, бу башка мәсьәлә. Ләкин һәрхәлдә зур вакыйгаларны зур ирләр берлә күрәмез» дигән фикерне җиткерә һәм тарихта зур эз калдырган ирләрнең (Тафтазани, Әфгани, Габди, Биги һ.б.) исемнәрен санап китә. Алар белән бер рәткә ул Габделнасыйр Курсавины һәм аның эшен дәвам итүче, фикри укучысы Шиһабетдин Мәрҗанине куя.

Җ. Вәлиди Ш.Мәрҗанинең Курсави эшчәнлегенә югары бәя бирүенә, аны заманының иң зур, мәшһүр акыл иясе санавына «гаҗәпләнү илә карарга юл калмый» дип белдерә. Мәрҗани фикерләренә кушылып, Курсавины «гәрчә ислам диңгезен дулкынландыручы бер куәт булмаса да, аның бер генә читен булса да хәрәкәткә китерүче зур бер тәэсири көч» дип атый.

Мәрҗанинең үзенә килгәндә, автор аны «Габделнасыйр чәчеп калдырган орлыкны тәрбия итеп үстерүче, аңа киң бер мәйдан бирүче» дип атый. Ш. Мәрҗанинең берничә дини мәсьәләнең каһарманы булып чыгуын искә алып, әлеге мәсьәләләргә (мәсәлән, ястү вакытын билгеләү һ.б.), галимнең аерым хезмәтләренә тирәнтен туктала, Мәрҗанидән өзекләр китереп, аның фикерләрен куәтли.

Җ. Вәлиди Ш. Мәрҗанинең татарлар өчен иң мөһим дип саналган биш хезмәте арасында аеруча билгелесе дип ике томлык «Мөстәфадел-әхбар»не атый, әлеге китапны «безнең тарихыбызның анасы дип әйтергә ярарлык әсәрләр» дип белдерә. «Аның (Мәрҗанинең. – Л.М.) мөхакәмә (хөкемендә. – Л.М.) һәм фикер йөртүендә шәдид (көчле, нык. – Л.М.) истикъляль (мөстәкыйльлек. – Л.М.), мөмтаз (башкалар белән чагыштырганда өстенрәк булган. – Л.М.) бер субъективлык бар», – дип яза. Ләкин шул ук вакытта, галим фикеренчә, Мәрҗанинең иҗади мирасына бәя биргәндә, һичшиксез, аның чорын, дәверен, әйләнә-мохитен истә тотарга кирәк. «Ул шул дәвернең бөек бер ире иде. Гомуми вә куәтле бер үсеш тарихына тугры килмәгәнлектән, үз куәте илә генә, үзенчә генә эш күрде. Күбрәк шул дәвернең тәэсирен, шул дәвернең эшен, шул дәвернең формасынча эшләргә мәҗбүр булганлыктан, үзен бу көннең ифкяр гомумиясенә (яралы, гарипләнгән халкына. – Л.М.) бер генә ягы илә яктыртып күрсәтә алды. Аурупа тәэсире дәверендә[2] булса, ихтимал, ул кадәр җилдләр калдыра да алмас иде, ләкин аның әсәренең тагын да күбрәк кыйсеме укылыр, тагын да ятылыр, бинаән галәйһи (шул сәбәпле. – Л.М.) ул тагын да күбрәк ягы белән ачылыр иде». Чорның галим фикере формалашуга йогынтысын билгеләп, Вәлиди мисал итеп Ш. Мәрҗанинең эшен дәвам итүче икенче бер танылган татар галимен – Р.Фәхретдинне китерә. Соңгысының фикри юнәлеше формалашуда, автор билгеләвенчә, Аурупа чорының тәэсире көчле; башка чорда яшәсә, ул бу кадәр зур уңышларга ирешә дә алмас иде.

Мәрҗанинең эшчәнлегенә бәя биреп, автор: «Шиһаб хәзрәт татар тарихы тиңдәшен күрмәгән бер ми, бер даһи иде. Заманы, мохите аның эшен, тәэсирен тиешле дәрәҗәсеннән күп киметте. Ләкин заман вә мохиттә булуы аның дәрәҗәсен, эшенең абруен зурайтты гына. Мохитендәге караңгылыкның куәтлелеге ул йолдызның тиешле дәрәҗәдә яктыртуына тыючы булды, фәкать шул ук куәтле караңгылык аның яктыруына ярдәм итте», – дип яза. Фикерен куәтләп, «Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен...» дигән шигъри юлларны өсти.

[2] Җ. Вәлиди татарларның һәм гомумән мөселманнарның фикри һәм әдәби тарихын икегә аерып карый: Европа тәэсиренә кадәр һәм Европа тәэсиреннән соң.

Мәрҗани һәм халык арасындагы бәйләнешнең ныклыгын, аның милләт тормышында тоткан урынын ассызыклап, Җамал Вәлиди: «Мәрҗани хәзрәтләре бәхтиярдер (бәхетле. – Л.М.): аны бүген 20 миллионлык бер халык үзенең иң мөһим бер әгъзасы санап, тәгзыйм (олылау. – Л.М.) белән яд итә (искә ала), бар кадәр көче илә намен (исемен. – Л.М.) куәтләргә тырыша. Бу милләт янә бәхтиярдер: аның тарихында Мәрҗани кеби галим вә хакыйкать мөҗаһидләре (көрәшче. – Л.М.) бар. Аның мазыйсы (үткәне. – Л.М.) бөтенләй үк буш бер сахра түгел, сирәк кенә булса да, күләгәле яшел, ямьле агачлар бар...» – дип яза.

Шул ук газетаның 1914 елгы 23 сентябрь санында «Шиһабетдин хәзрәт юбилее» дигән тагын бер шактый күләмле мәкалә дөнья күрә [6]. Бу мәкаләдә (авторы күрсәтелмәгән) юбилей үткәрү белән бәйле кайбер мәсьәләләргә тукталына.

Газета язуынча, Мәрҗани юбилеен үткәрү көннәре якынлашу сәбәпле, аны кабат кузгатырга, искә төшерергә тиешле күрелә. Бу мөнәсәбәттән «Кояш» газетасы авторларыннан берсе булган педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Бикколовның фикерләре китерелә. Гомумән алганда, шуны билгеләп үтү кирәктер, «Вакыт» газетасында башка татар һәм рус газета-журналларында басылган материалларга һәрдаим мөрәҗәгать итү, кайберләрен күчереп басу, шул рәвешле аларның таралыш даирәсен киңәйтү, аерым мәкаләләргә карата фикерен белдереп бару тәҗрибәсе күптәннән килә. Бу очракта «Вакыт» И. Бикколовның Мәрҗани юбилеен билгеләп үтүгә караган фикерләрен китерә. Бикколовның бу тантананы оештыру һәм уздыруга мөмкин кадәр күбрәк милләттәшләребезне һәм мөселман кардәшләребезне тарту мөһимлеген ассызыклавын, әлеге чараларның масштабын билгеләргә тырышып, «бу мөнәсәбәт илә Русиянең иң караңгы почмакларында яшәгән мөселманнар да файдаланырлык гомуми зур бер бәйрәм ясарга кирәк» дигән теләгенә уңай фикерен белдерә. Ибраһим Бикколов фикеренчә, Мәрҗани «хәзерге көндә дә руханиларымыз тарафыннан бөек ихтирам илә файдаланыладыр». Бу исә әлеге олы шәхесебезнең бәйрәмен халык бәйрәме иттереп үткәрергә мөмкинлек бирә. Моның өчен, Бикколов әйтүенчә, мәчет-мәдрәсәләрне катнаштырырга, шулар аркылы Мәҗани көнен халык бәйрәменә әйләндерергә мөмкин. «Мәрҗани безнең татар-төрек дөньясын әйләндереп алган җәһаләт (наданлык. – Л.М.) кальгасына беренче туп атучылардан, Гаспринский кебек бөек даһиларымызга хезмәт вә мәгариф орлыгы чәчәр өчен замен (алмашчы. – Л.М.) хәзерләп калдыручылардандыр», – дип белдерә [6].

Шул ук вакытта И. Бикколов әлеге юбилейны үткәрү, әзерлек өчен дә бик аз – 4 ай чамасы гына – вакыт калуы турында, теләгән эшләрне барысын да үтәп бетерү мөмкинлеге чамалы булуы турында яза. Шул сәбәпле, ди ул, Мәрҗани юбилеен өч елдан соң гына – 1918 елда гына үткәрергә дә мөмкин. Тик, Мәрҗанинең олуг дин галиме икәнен, хезмәтләрендә һәрдаим һиҗри ел исәбен генә файдалануын истә тотып, әлбәттә, искә алуны да 1915 елның гыйнварында үткәрү мәгъкуль күренә, дип яза.

Автор фикеренчә, бу гаять зур һәм җаваплы эшкә рәсми оешма, җитәкчелекнең рөхсәте белән тотыну мәҗбүри. «Безнең саф һәм милли, хәтта өлешчә дини әлеге эшебездә хөкүмәт тарафыннан тоткарлыклар, шаять, күрелмәс», – ди. Шул сәбәпле ул Казанның зыялыларыннан, җәмәгать хадимнәреннән һәм руханиларыннан торган махсус бер комитет төзергә, шул комитет аша юбилейга әзерлек эшләрен башлап җибәрергә кирәк, дип саный. «Вакыт» Бикколовның югарыда китерелгән фикерләре белән килешә, тик, илдә барган шактый катлаулы вазгыятьне истә тотып, бу бәйрәмне, мөгаен, вакытлыча кичектереп тору мәгъкуль булыр, дигән фикерне җиткерә.

Чынлап та, зур әзерлекләр күрелүгә карамастан, Мәрҗанинең юбилеен, алдан уйланганча, 1915 елның гыйнварында артык зурлап, тантаналы рәвештә үткәрү мөмкин булмый. Бу хакта Ш.Мәрҗанинең туган көнендә – 9 гыйнварда – «Вакыт» газетасында басылган мәкаләдә хәбәр ителә. «Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани көне» дигән әлеге язмада Ш.Мәрҗанине искә алу максатыннан «бу мөнәсәбәт илә, бөтен Русия мөселманнары арасында мөштәрәк (уртак. – Л.М.) гомуми бер бәйрәм ясалып, мәрхүмнең милләт вә ватанына кылган хезмәтләре искә төшерелергә тиеш иде. Фәукылгадә (гадәттән тыш. – Л.М.) әхваль сәбәпле, бу тантана кичектерелде. Шулай булса да, бу көн бу бөек галимгә ихтирам күрсәтелеп, мәсҗетләрдә җомга намазыннан соң дога кылырга, мәктәп вә мәдрәсәләрдә мәрхүмнең тәрҗемәи хәле вә фазаиле (күрсәткән яхшылыклары, казанышлары. – Л.М.) сөйләнергә тиешледер», – диелә [7].

Шулай итеп, төрки-татар һәм мөселман дөньясында танылган, дан һәм мәртәбә казанган мәшһүр галимнең 100 еллык юбилее шактый тыйнак кына үтеп китә. Ләкин бу хәл Шиһабетдин Мәрҗанинең ватаны, милләте һәм бөтен мөселман халкы алдында күрсәткән хезмәтләрен, аларның әһәмиятен һич кенә дә киметми. «Вакыт» газетасында дөнья күргән язмалар, 1915 елда «Мәрҗани мәҗмугасы» исеме астында күләмле, зур әһәмияткә ия булган фәнни җыентыкның басылып чыгуы бу фикерне тагын бер кат раслый. «Вакыт»ның 1915 елның 5 июнь санында «Мәрҗани мәҗмугасы»ның дөнья күрүе турында хәбәр ителә, аның эчтәлеге турында җентекле мәгълүмат бирелә [9].

Гомумән алганда, «Вакыт» газетасында Ш. Мәрҗанинең юбилее мөнәсәбәте белән басылган мәкаләләрдә аның татар тарихында гына түгел, бөтен Россиядә, алай гына түгел, барлык мөселман дөньясында зур галим, җәмәгать эшлеклесе, педагог булуына игътибар юнәлтелә. Әлеге язмалар мәшһүр галимебезнең фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген өйрәнүдә үзенчәлекле чыганак булып хезмәт итәләр.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Вәлиди Җ. Исмәгыйль бәк Гаспринский // Вакыт. 1914. № 1584. 14 сентябрь.
2. Вәлиди Җ. Мәрҗани // Вакыт. 1914. 18 апрель.
3. Гаспринский исеменә ядкяр // Вакыт. 1914. 13 декабрь.

4. Мәрҗани юбилее // Вакыт. 1914. 18 апрель.
5. Фәхретдин Р. Исмәгыйль бәк Гаспринский // Вакыт. 1914. 13 сентябрь.
6. Шиһабетдин хәзрәт юбилее // 1914. 23 сентябрь.
7. Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани көне // Вакыт. 1915. 9 гыйнвар.
8. Шиһаб хәзрәт Мәрҗани җәнабларының юбилее мәсьәләсендә даир // Идел. 1912. 21 февраль.
9. Яңа гына басылып чыгып ... // Вакыт. 1915. 5 июнь.

**Автор турында белешмә:** Мортазина Ләлә Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); lyalyamur@mail.ru

## «ГЕНИЙ, КАКИХ НЕ ЗНАЛА ИСТОРИЯ ТАТАР» (ГАЗЕТА «ВАКЫТ» О ЮБИЛЕЕ Ш. МАРДЖАНИ)

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье анализируются публикации, посвященные юбилею выдающегося татарского просветителя и ученого Шигабутдина Марджани, которые были опубликованы в газете «Вакыт» («Время»). Рассматриваются статьи, в которых раскрываются некоторые страницы биографии, научно-педагогическая и общественная деятельность Марджани, поднимаются проблемы подготовки и проведения юбилея ученого. Особый интерес представляют материалы, посвященные увековечению имени и научного наследия просветителя. Изучение этих публикаций дает возможность представления роли и места Ш. Марджани в тюрко-татарском и мусульманском мире в начале XX в.

**Ключевые слова:** Шигабутдин Марджани, татарская печать, газета «Вакыт», юбилей, увековечение памяти.

**Для цитирования:** Мортазина Л.Р. «Татар тарихы тиңдәшен күрмәгән даһи» («Вакыт» газетасы Ш. Мәрҗани юбилее турында) // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 2. С. 319–325. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.319-325

**Сведения об авторе:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

*Мортазина Л.Р.* «Татар тарихы тиңдәшен күрмәгән даһи»
(«Вакыт» газетасы Ш. Мәрҗани юбилее турында)

# «THE KIND OF GENIUS, HISTORY OF TATARS NEVER KNEW BEFORE» ("VAKYT" NEWSPAPER ABOUT SH. MARJANI'S ANNIVERSARY)

***L.R. Murtazina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

The article analyzes publications dedicated to the anniversary of the outstanding Tatar enlightener and scholar Shigabutdin Marjani, which were published in the newspaper "Vakyt" ("Time"). Articles that reveal Marjani's biography and his scholarly, pedagogical and social activities are discussed in the paper. The question of preparing and conducting the anniversary of the scholar is discussed. The materials devoted to the perpetuation of Marjani's name and his scientific heritage are of particular interest. The study of the given publications makes it possible to present the role and place of Sh. Marjani in the Turkic-Tatar and Muslim world at the beginning of the twentieth century.

**Keywords:** Shigabutdin Marjani, Tatar press, "Vakyt" newspaper, anniversary, perpetuation of memory.

**For citation:** Murtazina L.R. "The kind of genius, history of Tatars never knew before" ("Vakyt" newspaper about Sh. Marjani's anniversary). *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2018, vol. 3, no. 2, pp. 319–325. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.319-325

REFERENCES

1. Välidi Ç. Ismägyjl bäk Gasprinskij [Ismail bey Gasprinskiy]. *Vakyt – Time*. 1914. September 14. (In Tatar)
2. Välidi Ç. Märçani [Marjani]. *Vakyt – Time*. 1914. April 18. (In Tatar)
3. Gasprinskij isemenä yadkyar [The Memory of Gasprinskiy] *Vakyt – Time*. 1914. December 13. (In Tatar)
4. Märçani yubilee [Marjani's Anniversary] *Vakyt –Time*. 1914. April 18. (In Tatar)
5. Fähretdin R. Ismägyjl bäk Gasprinskij [Ismail bey Gasprinskiy] *Vakyt – Time*. 1914. September 13. (In Tatar)
6. Shihabetdin häzrät yubilee [Shigabutdin hazrat's Anniversary]. *Vakyt – Time*. 1914. September 23. (In Tatar)
7. Shihabetdin häzrät Märçani köne [The Day of Shigabutdin hazrat Marjani]. *Vakyt – Time*.1915. January 9. (In Tatar)
8. Shihab häzrät Märçani çänablarynyñ yubilee mäsäläsendä dair [To the question of Shigabutdin Marjani hazrat's anniversary]. *Idel – Idel*. 1912. February 21. (In Tatar)
9. Yaña gyna basylyp chygyp ... [Just released]. *Vakyt – Time*. 1915. June 5. (In Tatar)

**About the author:** Lyalya R. Murtazina is a Candidate of Science (Pedagogy), Leading Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru